
# Хода сезне кадерләсен

Запись Масгуды Шамсутдиновой



Укыйм әле, укыйм әле, күңелләрегез ачылсын,
Сигез оҗмах эчләрендә ризыкларыгыз чәчелсен.
Тәмам сөям үзегезне кабул итеп сүзегезне,
Бер Ходаем якты кылсын Кыяматтә йөзегезне.
Карасам йөзегез якты, сөйләгән сүзегез татлы,
Дөнья гизеп эзләсәң дә табылмас бу мәҗлес хәтле.
Мәҗлесләрнең кадрен белик, Ходага күп зекер кылыйк,
Дин Исламда булганлыкка шатланышып шөкер кылыйк.
Утырмаек фекер белән, утыраек зекер белән,
Хуш нигъмәтләр хәзерләнгән, ашадык без шөкер белән.
Мәҗлес хәзерләүчеләргә Ходаем Рәхмәтен салсын,
Сират күпрен ансат кичеп җәннәт ишегенә барсын.
Мәҗлес җыйган хуҗаларның нурлы әйлә каберләрен,
Бу мәҗлесләр бик кадерле, бик беләек кадерләрен.
Безне зурладыгыз бүген зур мәҗлес хөрмәте белән,
Хода сезне кадерләсен Иманның Нурлары белән.
Җәннәт сезне каршы алсын Ходаның рәхмәте белән.
Мәҗлес ясап хәзерләнгән - безнең өчен зур хөрмәтләр,
Рәсүлюлла сезгә кылыр Кыяматтә шәфәгатьләр.

©